# КАРАР

**2019 елның 12 декабре** **№ 4**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советының 2019 елның 31 октяберндәге 37 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү һәм үткәрү турында Нигезләмә нигезендә, 2019 елның 11 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез

- 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау, Яңасала авылы, Үзәк урамның 46 нчы йортыннан алып Яшьләр урамы 16 нчы йортка кадәр.

- 2019 елның 13 нояберендәге 2 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» карарны юкка чыгарырга

ризамы»?

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 213 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 115 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 107 кеше тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда катнашкан 8 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез

- 2020 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау, Яңасала авылы, Үзәк урамның 46 нчы йортыннан алып Яшьләр урамы 16 нчы йортка кадәр.

- 2019 елның 13 нояберендәге 2 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Яңасала авылында халык җыены нәтиҗәләре турында» карарны юкка чыгарырга

ризамы»?

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы А. И. Сафин